# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**"Инвалидлар һәм социаль яклауга аеруча мохтаҗ гражданнар өчен эш урыннары квоталау һәм резервлау турында" Татарстан Республикасы Законының 6 статьясына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2013 елның 28 июнендә
кабул ителде

**1 статья**

"Инвалидлар һәм социаль яклауга аеруча мохтаҗ гражданнар өчен эш урыннары квоталау һәм резервлау турында" 2006 елның 24 июлендәге 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 6 статьясындагы 2 өлешенә (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 7 (I өлеш); 2012, № 7 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 пунктта "(алга таба – эш урыннары квоталарын һәм резервлауны билгеләү турында карар)", "һәм әлеге карарларның үтәлеше турында Татарстан Республикасының халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте органнарына мәгълүмат бирергә" сүзләрен төшереп калдырырга;

2) түбәндәге эчтәлекле $1^1$ пункт өстәргә:

"$1^1$) инвалидларны һәм социаль яклауга аеруча мохтаҗ гражданнарны эшкә урнаштыру өчен булдырыла яисә бүлеп бирелә торган эш урыннары турында белешмәләр булган локаль норматив актлар кабул итәргә;";

3) 2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"2) ай саен Татарстан Республикасының халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте органнарына вакантлы эш урыннары (вазыйфалар) булу, инвалидларны эшкә алу өчен билгеләнгән квота нигезендә инвалидларны эшкә урнаштыру өчен булдырылган яисә бүлеп бирелгән эш урыннары турында, бу эш урыннары, инвалидларны эшкә алу квотасы үтәлеше турында белешмәләр булган локаль норматив актлар хакында мәгълүматны да кертеп, мәгълүмат тапшырырга;";

4) түбәндәге эчтәлекле $2^1$ пункт өстәргә:

"$2^1$) Татарстан Республикасының халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте органнарына хезмәткәр эштән җибәрелгән көннән алып 10 көн эчендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән форма буенча инвалидларны һәм социаль яклауга аеруча мохтаҗ гражданнарны эшкә урнаштыру өчен резервлана торган эш урыннарының санын билгеләү турындагы карарлар кысаларында бүлеп бирелгән яисә булдырылган бушый торган эш урыннары хакында мәгълүмат тапшырырга;".

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2013 елның 10 июле
№57-ТРЗ